ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ФЕВРАЛЬ,
2016 нчы ел

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!

№6 (20)





**14—Гашыйклар көне**

**23— Ватанны саклаучылар көне**

## ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ БЕЛӘН!

23 нче февраль көнне илебез төп бәйрәмнәрнең берсе – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә. Иңнәренә погон таккан хәрбиләребезнең генә түгел, «ил», «Ватан», «бурыч» дигән сүзләргә битараф булмаган һәрбарчабызның бәйрәме бу.

Хөрмәтле ир-атларыбыз! Барыгызны да Ватанны саклаучылар көне белән эчкерсез котлыйбыз! Сезгә һәм сезнең гаиләләргә тыныч күк йөзе, нык сәламәтлек, уңышлар һәм иртәгәсе көнгә ышаныч телибез! Ил барда — егет хур булмас, диләр. Сезгә һәрвакыт ихтыяр көче, гаилә бәхете юлдаш булсын! Тормыш сынауларына бирешмичә, һәрвакытта да чын ирләр булып калуыгызны телибез! Илебез сагында торучы кыю, курку белмәс егетләр булганда илебез халкы тыныч йоклар, күгебез гел аяз булыр.

*Сез булганга имин булып ата таңнар.*
*Тыныч-матур тормыш белән үтә айлар.*
*Бәйрәмегез котлы булсын ир-егетләр.*
*Мәңге тыныч, имин торсын җирләр-күкләр.*

**Гөлшат Гайсина**

### *Ялган һәм чын батырлык*

Нәрсә ул батырлык? Кешеләр "батырлык" төшенчәсенә нинди мәгънә салалар соң? Батырлык ул – кыюлык, гайрәт, тәвәкәллек, кирәк булганда, үз-үзеңне аямау. Ә ялган батырлык булырга мөмкинме соң? Мисаллар ярдәмендә шул турыда уйланып карыйк.

Шулай итеп, кемне соң без "батырлык" төшенчәсенә туры килгән батыр дип әйтә алабыз? Андый батыр дип без котырган янгын эченнән төтенгә буылган сабыйны алып чыгучы янгын сүндерүчене (ә ул бит иптәшләренең янгынны сүндереп беткәннәрен көтәргә, аннан соң гына да янгын урынына керергә мөмкин иде) әйтә алабыз.

Төрле илләрдә булгалап торган хәрби бәрелешләр вакытында, снарядлар шартлаганда һәм пулялар сызгырганда, яраланган кешеләргә ярдәм күрсәтүче табиблар да – чын батырлар.

Бер доза наркотик яки берникадәр сумма акча өчен кеше үтерергә әзер торган бандит юлына аркылы баскан милиционер да, бәхәссез ки, чын батыр.

Әмма ялган батырлыкның да мисаллары күп. Мәсәлән, үзенең шартлаткычы белән беринди гаепсез йөзләрчә кешенең гомерен өзгән террорист-камикадзеның "батырлыгы". Аларның бу гамәлен кайбер илләрдәге радикаль юнәлешле төркем кешеләре батырлык дип санаса да, бу безнең өчен аңлашылмаган, ялган батырлык. Кешенең гаепсезгә тамган бер генә тамчы каны да хәтта иң бөек максатларны да аклый алмый.

Минем чираттагы мисалым, бәлки, кемнәргәдер ялгыш дип тоелыр. Әмма мин хулиган дусларын яклаучы, аларның әшәкелекләрен олылардан, укытучылардан яшереп килүче малай яки кыз да, бандит кебек үк, ялган "герой" дип уйлыйм. Бу чагыштыру бераз катгыйрактыр, бәлки кырыстыр, тик нәкъ менә шундый кечкенә, әшәке адәм актыгыннан зур, канкойгыч бандит-"герой" үсеп чыга да инде. Бу – минем, кайберәүләр өчен бәхәсле дә булган шәхси фикерем.

**Алсу Хайбуллина**

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Кочлелеген белән горурланма—кешелеген белән горурлан! | 2 |
| Батырлык мәктәптә тәрбияләнә | 3 |
| Якыннан таныйшыйк! | 4 |
| Бардык, катнаштык, җиңдек! | 5 |
| Көлке хикмәте | 6 |
| «Ялкын» җиңүчеләре! | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |

# 14 нче февраль—Гашыйклар көне!

Бу бәйрәмне белмәгән, аның турында ишетмәгән кеше юктыр. Әлеге бәйрәм елдан-ел киңрәк тарала, кем-кем, ә яшьләр аны аеруча көтеп ала. Хәер, кем генә мәхәббәт утында янмады һәм көймәде икән?! Әлеге көннең шатлыклы мизгелләре дә күп бит: нәкъ менә бүген күпләр бер-берсенә мәхәббәтләрен аңлата, өйләнешергә тәкъдим ясый, сөйгән ярларын үзенчәлекле бүләкләр белән сөендерә, ачуланышкан парлар исә яңадан кавыша.

Тарих битләренә күз салсак, әлеге бәйрәмнең барлыкка килүе изге Валентин белән бәйләнгән. Легендалар буенча, изге Валентин безнең эраның XIII гасырында Рим империясендә туган. Бу елларда император Юлий Клавдий II легионерларына өйләнергә рөхсәт итмәсә дә, Валентин, императорның карарына каршы килеп, гашыйк парларга чиркәүдә никах укуын дәвам иткән. Валентин шушы эше өчен төрмәгә утыртыла һәм үлемгә хөкем ителә. Төрмәдә утырганда, сукыр кызы булган бер сакчы Валентиннан кызын дәвалавын сорый. Савыккач исә, сакчының кызы Валентинга үлеп гашыйк була. Җәза көне килеп җиткәч, Валентин кызга хушлашу хатын яза, ахырдан, «Синең Валентиның», дип имзасын да калдыра. «Валентинка» дигән сүз дә шул вакытлардан бирле килә. 14 февраль көнне Валентинны үтерәләр. Хәзер исә әлеге көнне Изге Валентин яки Гашыйклар көне дип атыйлар. Бу мәхәббәт тарихын хәзер инде күпләр белми дә.



## Көчлелегең белән горурланма, кешелегең белән горурлан!



“Болгар” радиосыннан, милләтебезнең асыл затлары турында сөйләгәннән соң, көн дә: “Син үз халкың, илең өчен нәрсә эшләдең?” дигән сорауны яңгыраталар.

Без дә укучыларыбыз белән шул сорауга җавап эзләдек, дөресрәге, илеңнең, халкыңның игелекле баласы булу өчен нинди шартлар үтәлергә тиешлеген өйрәндек. 15 нче февраль – татар халкының асыл уллары туган көн. Патриот-шагыйрь Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты буенча эзләнү эшләре башкарган укучылар Гафурова Алия белән Хәйбуллина Алсуның чыгышыннан соң, 38 яшендә батырларча һәлак булган әдип үрнәгендә игелек эшләү гомер озынлыгыннан тормавын ачыкладык.

Әһлиуллин Аязның якташыбыз Гакыйль Сәгыйров исемендәге музей белән интернеттагы сайт аша таныштыруы, Шәрәфетдинова Адилә һәм Абдрахманова Рәзиләнең шагыйрь шигырьләрен күңелдән сөйләүләре дә бик урынлы булды. Гомерен урын өстендә бер хәрәкәтсез үткәргән көчле рухлы якташыбыз. Шулай да авыруы аңа халкыбызның бөек улы булып танылырга комачаулый алмаган дигән нәтиҗәгә килдек без. Әлеге көнне туган тагын бер илаһи талант иясе - җырчыбыз Илһам Шакиров җыр-моңнарын тыңладык. Бер уйласаң, гап-гади нәрсә кебек бит ул җыр һәм җырлау. Юк икән, җыр белән дә халкыңа хезмәт итеп була икән бит. Моңлы сандугачыбыз бөтен гомерен милләтебезгә багышлады, җыры белән халкыбызны бердәм яшәргә чакырды. Әлеге чарада Фома авылы һәм мәктәп китапханәчеләре Розалия Таһирова белән Айсылу Гафуроваларның катнашулары да сорауларга җавап табарга булышты. Әйе, һәркем үз халкы, үз иленең игелекле баласы була ала икән. Моның өчен гадәттән тыш сәләткә ия булу кирәкми, бары теләк, максат, кешелекле булырга гына кирәк. Муса Җәлил әйткәнчә, көчлелегебез белән түгел, кешелегебез белән горурланып яшик.

**Гөлүсә Әһлиуллина, Резедә Сафиуллина,**

**Фома урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучылары**

# Якыннан танышыйк!



**Укучыларның сорауларына татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы җавап бирә.**

**- Гөлүсә Дамировна, укытучы булу — балачак хыялымы яки үсә төшкәч барлыкка килгән теләкме?**

- Балачакта хыяллар күп булды минем. Телевизор эченә кереп җырлыйсым да килде, ак халатлы табиб булырга да теләдем, фигуралы шуучы булсам шәп булыр дип уйладым, әтием кебек ватык техниканы оста төзәтә белү дә кызыктырды мине… Ә шулай да кечкенәдән укытучылы уйнау үзенекен итте—8 сыйныфны тәмамлау белән Яр Чаллыга - педучилищега юл тоттым. Анда укуыма әле дә сөенәм, чөнки бу уку йорты мине күп нәрсәгә өйрәтте.

**– Ничек уйлыйсыз, укытучы һәр балага да тигез карый аламы?**

- Укытучы һәр балага шәхес итеп карый, аның фикерен тыңлый, балага тирән белем һәм яхшы тәрбия бирүгә бөтен көчен куя. Ә менә балалар укуга төрле мөнәсәбәттә булырга мөмкин. Тырыш, максатчан укучыларның гына сәләтен үстереп була, битарафлар белән эшләү кыен.

**- Сез шигырьләр дә иҗат итәсез. Бу шөгыль белән кайчан кызыксына башладыгыз?**

- 4 нче сыйныфта үземчә «бик шәп шигырь» язган идем, тик аны «Яшь ленинчы" газетасында бастырмагач, бу шөгыльгә кул селтәгән идем. Аннан укытучы булып эшләгәндә хезмәтемдә кирәк булганлыктан, кабат кулыма каләм алдым.

**— Гөлүсә апа, Сезнең тормышыгызда иң бәхетле көнегез нинди?**

- Шөкер, бәхетемә күз тимәсен. Мин тормышымнан канәгать. Иңиң бәхетле көнем , мөгаен, беренче тапкыр әни булган көнемдер.

**— Газета укучыларыбызга теләкләрегез?**

- Дөньяда яшәвебез—үзе зур бәхет, Шуңа да һәр көнне сөенеп, мәгънәле яшәргә кирәк. Максат куеп, аңа ирешергә, омтылу мөһим. Һәркем рухи һәм физик яктан - сәламәт яшәсен, күңеле, теле һәм йөзе—матур, бәхете—гомерле булсын, гомере бәхетле үтсен.

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

# Батырлык мәктәптә тәрбияләнә

22 нче февраль көнне мәктәбебездә, Ватанны саклаучылар көненә багышлап, хоккей турниры үтте. Һәм менә икенче ел рәттән Әфганстанда сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан Түбән Камада яшәүче Илгиз Гыйләҗев призларына үтте. Җиңүчеләргә кубоклар һәм акчалата бүләкләрне ул әзерләде һәм, әлбәттә инде, бу көнне мәктәбебезнең иң кадерле кунакларның берсе булды. Хәер, Илгиз Гәрәй улы —мәктәбебездә даими кунак. Турнирның ачылу тантанасыннан соң укучыларыбыз катнашында үткән Батырлык дәресендә ул өч дистә елдан артыграк элек булган вакыйгаларга әйләнеп кайтты. Зирекледән 5 бала анасы, шуларның өчесен Әфган сугышына озатып көтеп алган Әминә апа Шәйхетдинованың күз яшьләре дә укучыларга сугыш китергән афәтләрнең бөтен тирәнлеген аңларга ярдәм иткәндер. Батырлык дәресләрендә укучылар аларны тагын бер кат телгә алып, батырлык, Ватан сакчысы булу дигән төшенчәләрнең асылы хакында сөйләштек. Шунысы сөенечле: бәйрәмгә 70 ләп эти килгән иде.

Бу вакытта исә шугалакта Фома, Чулпан, Яңа Иглай мәктәпләре командалары арасында «кайнар» көрәш барды. Ярышларда хоккейчы егетләребез сынатмадылар, беренчелек аларда булды. Турнир тәмам, азактан—сугышчы-интернационалистлар белән истәлеккә фото. Ә яшь хоккейчыларның һәркайсының — җиңүчеләр һәм җиңелүчеләрнең дә йөзләрендә — горурлык. Ватан сакчылары күне алдыннан бозда сугышчы-интернационалистлар кубогы өчен көч сынышу үзе үк чын батырлык бит ул.



## Бардык, катнаштык, җиңдек!



Туган телебездә җиңел аралашкач, укытучыларыбызның кызыклы дәресләрендә актив катнаша алгач, татар теле бик җиңел фән шикелле тоела иде. Ә менә олимпиадага әзерләнә башлагач, үзебез өчен бик күп серләр ачтык, ана телебезнең бөеклегенә, байлыгына сокландык. “Тырышкан табар, ташка кадак кагар”, дигәндәй, районда җиңү яулап, республика турында катнашу бәхетенә ирештек. Бәйге зур оешканлык белән узды. Анда безгә төрле районнардан килгән иң көчле, сәләтле яшьтәшләребез белән көч сынашырга туры килде. Әлбәттә, укытучыларыбыз Гөлүсә Дамировна Әһлиуллина һәм Резедә Дамировна Сафиуллиналарның безгә төпле белем биреп, көндәшлеккә сәләтле шәхес итеп тәрбияләүләре куйган максатыбызга ирешергә насыйп итте. Безнең уңышыбызга барлык мәктәп коллективы сөенгән икән. Әнә ничек каршы алдылар бит алар безне. Җитәкчеләребез белән бергә иртән мәктәпкә килеп керүебез булды, шаккаттык: барысы да кулларына чәчәкләр, шарлар тотып, “тере коридор” ясап тезелгәннәр. Күңелле музыка астында, “Котлыйбыз!” дип елмаеп торучылар алдыннан узганда, күңелләрдә горурлык хисе янды. Туган телебезне ихтирам итәргә, сакларга һәм үстерергә кирәклегенә кабат инандык. Киләсе елларда да сынатмабыз дип ышанып калабыз.

**Шарапова Ләйсән, Гафурова Алия**

**14 февраль көнне Нурлат шәһәрендә “Чаңгы юлы – 2016” массакүләм чаңгы ярышлары узды.**

Мәктәп укучыларыннан алып, муниципаль хезмәткәрләр, җитәкче урыннарда эшләүчеләр, ветераннар да басты чаңгы юлына. Безнең мәктәп тә бу ярыштан читтә калмады. Гәрәев Фәиз, Аглиуллин Аяз кебек укучыларыбызның бу ярышта бик теләп катнашуы яшьләрнең спортка битараф булмавын күрсәтеп тора. Укытучыларыбыз: Хузахметова Г.С., Ахметова Р.А., Билданова Ф.В., Садртдинова Р.Н., Замалеев А.К. та башкалардан калышмадылар. Ә инде Айрат Замалеев III урынны яулады. Табигатьанабыз да, кояшлы матур көн бүләк итеп, спорт сөючеләрне сөендерде.




**5 нче февраль көнне күптән көтеп алган “Студентлар белән очрашу” кичәсе булып үтте.** Әлеге чарага мәктәбебезне сагынган, укытучыларны хөрмәт иткән укучылар килгән иде. Очрашуга килгән студентлар өлкән сыйныф укучыларын үзләре белеем алган уку йортлары белән, анда керү, яшәү шартлары белән таныштырдылар, укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр. Кичәнең икенче өлеше кызыклы уеннар белән дәвам итте.



# Көлке хикмәте



*****

-Таһир, син мине яратасыңмы?
– Яратам!
– Ә минем өчен гомереңне дә бирә алыр идеңме?
– Гомерне бирсәм, ул чагында сине кем генә яратыр соң, җаный?

****

Доктор авыруга:
- Я ничек, хәтерегез яхшырдымы?
Авыру:
- Ә син кем буласың? Нәрсә дип миңа бәйләнәсең?

****

Ике корт, тизәктән башларын чыгарып, сөйләшеп торалар ди:
- Әти, әнә тегендә бүтән кортлар алма эчендә яшиләр... Ә нигә без тизәк эчендә?
- Их, улым, аңламыйсың шул әле син... Туган җирдән газиз берни дә юк дөньяда...

* * *

Унөч яшьлек кызны әнисе тирги:
- Ах, син, юньсез кызый! Әтиең белән без сине эзләп, бөтен дискотекалар, кафелар, барлар буйлап йөгереп йөрдек! Ә син монда подъезд төбендә комлыкта уйнап утырасың икән!!

****

Әбисе белән оныгы телевизор карап утыралар, ә анда кош гриппына каршы көрәшне, йорт кошларын күпләп юк итүне күрсәтәләр. Кисәк кенә оныгы:
- Әби, ул кошларны нигә үтерәләр? - дип сорый.
- Чирләмәсеннәр өчен! - ди әбисе

****

Диңгез буенда ял итүче берәү, өч көн тоташ яңгыр яуганнан соң, кайтырга җыена башлый.
- Нигә вакытыннан алда җыенасың? - дип сорый аннан күршесе.
- Мондагы яңгыр үзәккә үтте...
- Сезнең якта да шундый ук яңгыр ява лабаса.
- Аның бездәгесе очсызгарак төшә шул.

*****

Операция өстәлендә яткан авыру хирургтан сорый:
- Әйтегез әле, бу операциядән соң мин скрипкада уйный алырмынмы?
- Әлбәттә, уйный алырсыз.
- Чынмы?
- Әйе, әйе!
- Кызык кына операция икән, - дип куя авыру. - Беркайчан скрипкада уйнаганым булмады югыйсә...

### Хәрби күнекмәләр һәм җыр

10 нчы февраль көнне мәктәбебездә совет чорыннан яшәп килгән **Хәрби күнекмәләр һәм җыр конкурсы** бәйрәм дәрәҗәсенә күтәрелеп үтте. Чын солдат дөрес басу күнекмәләре алырга тиеш. Безнең кызларыбыз һәм егетләребез үзләрен барлык яктан да төз, матур солдатлар итеп тоттылар.

**Таһирова Гайшә**




### “Елның сыйныф җитәкчесе – 2016” конкурсы

11 нче февральдә Нурлат районы Якушкино урта мәктәбендә “Елның сыйныф җитәкчесе” бәйгесенең беренче туры үтте. Безнең мәктәпне башлангыч сыйныф укытучысы **Фәхретдинова Равидә Нәгыйм кызы** тәкъдим итте .



# Әфганстан—йөрәк ярасы

6 нчы февраль көнне VI сыйныфта **"Әфганстан – йөрәк ярасы"** исемле ачык тәрбия сәгате үтте. Чараны тарих укытучысы, VI сыйныф житәкчесе Фәхриева Гөлфия Якуп кызы әзерләде. Сыйныф сәгате ерак Әфганстан жирендә гомере өзелгән, мәңге яшь булып калган солдатлар һәм ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булып яшәүче исәннәргә багышланды.



Жир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын! Яшь егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен, ата-аналар кайгы яше түкмәсен иде. Кеше жиргә яшәү өчен яратылган. Ә сугышлар алар безнең йөрәк ярлары, мәңге төзәлмәс йөрәк яралары.

## «Ялкын» жиңүчеләре



Алдан хәбәр итүебезчә, 7 нчеләр сыйныф житәкчеләре Гөлүсә Әһлиуллина турындагы видеоэш белән “Ялкын” журналы үткәргән “Иң гүзәл кеше икәнсез” конкурсында жиңү яулаганнар иде һәм бүләкләү тантанасына Казанга чакыру алдылар. Район мәгариф бүлеге һәм мәктәп житәкчелегенең ярдәме белән Rазанга барысының да бару мөмкинлеге булды. Жиңүләре өчен укучыларыбыз Грамота һәм истәлекле бүләк белән билгеләп үтелгән. Ә Казанга барулары кызыклы сәяхәт буларак та исләрендә калачак, чөнки бу көн башкаланың истәлекле урыннарында да булырга өлгергәннәр жиденчеләр.

**Пешекче – егетләр һөнәреме?**

Пешекче – егетләр һөнәреме, дисездер. Пешекче һөнәренә өстән генә карау дөрес түгел. Үз эшеңне яратсаң, күп баскычларга, биеклекләргә күтәрелергә була. Пешекче ул рәссам кебек: бизәү, ясау, тудыру белән шөгыльләнә.

Абыемның мөстәкыйль рәвештә иң беренче пешергән ризыгы трубочкалар иде. Беренче коймак төерле була, дисәләр дә, абыемның сые искиткеч тәмле килеп чыккан иде, хәтта тәмен хәзер дә тоям кебек. Аннан соң торт пешерде, анысы да тел йотарлык булды. Шуннан бирле көннән-көн остара гына бара ул. Абыема кызыгып, мин дә аңа кушылдым. Кайвакыт бер үк әйберне икебез пешереп карыйбыз да әти-әнигә тәкъдим итәбез. Ул әле баллы ризыклары белән тәмле тамаклы дусларын да сыйларга ярата. Пешергән ризыклары авыз итеп караган һәркемгә ошый. Илшат абыем татлы камыр ризыкларын үзенчәлекле итеп бизәп табынга бирә белә, шуңа күрә аңа үз бәйрәмнәренә заказ бирүчеләр дә бар. Шулай итеп абыем бүгеннән үк үз куллары белән хәләл акча эшли. Табыш та китерә алучы әлеге һөнәр нишләп егетләрнеке булмасын дип уйлыйм мин. “Пешекче эше һөнәр түгел, сәнгать”, - диюләре белән дә килешәм.

**Гайсина Гөлшат.**

**Шаккатмалы хәл**

Бер мәзәкне беләсезме икән. Берәү: “Мин хәзер чаңгыда шумыйм, гимнастика белән дә шөгыльләнмим, спортны ташладым”, - дигән. Сәбәбен болай аңлаткан: “Телевизор ватылды!” Чыннан да, кайберәүләр спорт белән шөгыльләнүне ярышларны экраннан карау дип кенә аңлыйлар.

Беркөнне сыйныф сәгатендә “Интернет, телефон һәм без” дигән темага сөйләшкәннән башлап, ирексездән, әлеге әйберләргә мөнәсәбәтебез турында уйланып йөри башладым. Чыннан да, күнебезнең бик күп өлеше шул әйберләргә текәлеп карап үтә икән бит. Әйе, әңгәмә вакытында без заман техникасының бик күп файдалы якларын таптык. Дөрес файдаланмаганда зыянлы булуы турында гына уйлап бетермибез икән. Әти-әни, әби-бабайларның фотосурәтләрен карап, бик кызыктым әле: алар гел табигать кочагында булганнар. Бәлки, безгә дә шулай итәргә кирәктер, дип язып куйдым да, телефоныма смс хәбәр килгәч сискәнеп куйдым...

**Аяз Әһлиуллин**

**Февраль аенда туган көннәрен билгеләп үтүче**

**директорыбыз**

**Сафиуллин Хәлим Салихович,**

**укытучыларыбыз:**

**Садртдинова Рузилә Нурисламовна,**

**Әһлиуллина Нурзия Маратовна**

**техник хезмәткәребез:**

**Сәфәргалиева Әнисә Сәлимовна!**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!







Февраль аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:

*Гатин Илнур, Салахова Әдилә, Галимов Инсаф, Нямаева Алина, Минегулов Илсур, Гайфуллина Фидалия, Назмутдинова Энҗе, Шарапова Лиана, Салахова Алинә!*

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хәйбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Юнысова Виктория, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.